| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТА МАЙДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ МӘЙДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | |
|---|---|
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
| 14.03.2017 | № 7 |

с. Майдан

Мәйдан авыл җирлеге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында 2017 елның язгы чорында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында

“Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында” 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Мәйдан авыл җирлеге Уставы нигезендә, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының язгы чорда җимерелүләрдән саклануын тәэмин итү максатларында,

Карар бирәм:

1. 2017 елның 15 апреленнән 15 маена кадәр Мәйдан авыл җирлегенең гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буенча һәр күчәргә рөхсәт ителгән түбәндәге йөкләнештән артып киткән транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертергә:

1.) Камилләштерелгән өслекле автомобиль юллары өчен:

- бер күчәрле транспорт чарасы өчен - 7,0 тонна;
- ике күчәрле транспорт чарасы өчен - 6,0 тонна;
- өч күчәрле транспорт чарасы өчен - 5,0 тонна;

2). Күчеш типтагы өслекле автомобиль юллары өчен:

- бер күчәрле транспорт чарасы өчен - 5,0 тонна;
- ике күчәрле транспорт чарасы өчен - 2,0 тонна;
- өч күчәрле транспорт чарасы өчен - 1,0 тонна;

2. Вакытлыча чикләү түбәндәгеләргә кагылмый дип билгеләргә:

- “Халыкара автомобиль ташуларны гамәлгә ашыруны дәүләт контроле турында һәм аларны үтәү тәртибен бозган өчен җаваплылык турында” 1998 елның 24 июлендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре нигезендә гамәлгә ашырыла торган халыкара йөкләр ташу;

автобуслар белән пассажирлар йөртү;

азык-төлек продуктларын, хайваннарны, дару препаратларын, орлык фондын, ашламаларны, почта һәм почта йөкләрен ташуны;

ягулык (бензин, дизель ягулыгы, судно ягулыгы, реактив двигательләр өчен ягулык, топ мазут, газ ягулыгы) ташый торган 16 тоннага кадәр йөк күтәрү чаралары ;

стихияле бәла-казаларның яисә башка гадәттән тыш хәлләрнең нәтиҗәләрен бетерү өчен кирәкле йөкләрне ташу;

Татарстан Республикасы Эчке эшләр Министрлыгының региональ әһәмияттәге автомобиль юллары өчен дәүләт юл хәрәкәте иминлеге инспекциясе идарәсе һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юллары өчен җирле үзидарә органнары белән килештереп, Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы Министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә авария-торгызу һәм ремонт эшләрен башкарганда кулланыла торган юл-төзелеш һәм юл-эксплуатацияләү техникасын һәм материалларны транспортировкалау.

3. Россия Федерациясенең Юл хәрәкәте кагыйдәләрендә каралган "Транспорт чарасы күчәренә туры килә торган массаны чикләү" 8.20.1 һәм 8.20.2 "Транспорт чараларының тележкалары тибы" өстәмә мәгълүмат билгеләре белән 3.12 юл билгеләрен куеп хәрәкәтнең вакытлыча чикләнүен тәэмин итергә;

4. Россия Эчке эшләр Министрлыгының «Югары Ослан» бүлегенә (Хохорин О.Е.), юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенә (Багаутдинов Р.А) Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү режимын үтәүне тикшереп торуны тәкъдим итәргә.

5. 2017 елның 16 мартына кадәр җирлекнең мәгълүмат стендларында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында вакытлыча чикләүләр кертү турында мәгълүмат урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы В.В.Михеев